**ГЛАВА МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

---

2023 елның 15 ноябре 5 номер

## КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегенең Матюшино торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. . Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023елның 28 ноябрендә 10 сәгатькә билгеләргә.

2. Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023елның 29 ноябрендә 10 сәгатькә билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Матюшино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Матюшино торак пунктында Грибная урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юлны ремонтлау: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү, коеларны ремонтлау, технадзор хезмәтләре) ,,

-Матюшино торак пунктында Садовая урамы буенча юл-урам челтәрен (смета буенча тротуар төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү, технадзор хезмәтләре) норматив хәлгә китерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Матюшино авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Матюшино**
**авыл җирлеге Советы рәисе: Н.И.Миннуллина**